| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАРШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАРШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2019 Шаршады авылы номер 20

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге
автомобиль юлларында зур йөкле һәм
гусеницалы транспорт хәрәкәтен тыю турында

Шаршады авыл җирлегенең урам-юл челтәре сакланышын тәэмин итү һәм аның массакүләм җимерелүен кисәтү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-3 номерлы ТР Законы һәм Шаршады авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 21 октябреннән Шаршады авыл җирлеге урамнарында зур йөкле һәм гусеницалы, йөкле яки йөксез, тагылма җайланмаларны да кертеп күчәренә рөхсәт ителгән йөкләнеше 3,5 тонна һәм артыграк булган барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен тыярга.

2. Әлеге чикләүнең гамәлдә булуы түбәндәге автотранспорт чаралары хәрәкәтенә кагылмый:

- пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмалар;

- Әгерҗе муниципаль районы администрациясенең сәламәтлек саклау һәм мәгариф идарәләре заявкалары буенча медицина учреждениеләренә, балалар бакчаларына, гомуми белем мәктәпләренә азык-төлек китерүче;

- Әгерҗе муниципаль районы администрациясенең гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы эшләре буенча

Идарәсе тарафыннан расланган исемлек буенча гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен булдырмау яисә бетерү белән бәйле транспорт;

-янгын сүндерүне гамәлгә ашыручы махсус билгеләнештәге;

- почта һәм почта йөкләре ташучы махсус билгеләнештәге;

-халык һәм предприятиеләр өчен сыекландырылган газ ташучы махсус билгеләнештәге;

-каты көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю һәм чыгару буенча эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган предприятиеләр транспорты.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән үлчәү параметрларына туры килүче транспорт чараларының җирлек урам-юл челтәре буенча йөрүе бары тик Шаршады авыл җирлеге администрациясе биргән махсус рөхсәте булган очракта гына рөхсәт ителә.

4. Шаршады һәм Сәхрә урамнары буйлап «3,5 тоннадан артык йөк транспортына керү тыелган» һәм «урап үтү» табличкаларын урнаштырырга:

-Зәйнетдинов урамы буенча Әгерже-Кр.Бор төп юлы ягыннан;

- Зәйнетдинов урамы буенча Шаршады авылы зираты ягыннан;

- Шаршады авылы зираты ягыннан Урманчылар урамы буйлап;

- Әгерже-Кр.Бор төп юл ягыннан Сәхрә авылында Нариман урамы буенча.

5. Шаршады авылындагы урап уза торган юл буенча Урманчылар урамындагы йөк транспорты хәрәкәте маршрутын билгеләргә.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсенә әлеге карар гамәлдә булган чорда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә:

6.1. Шаршады авыл җирлегенең урам-юл челтәре буенча автотранспорт хәрәкәте режимын контрольдә тотуны оештырырга.

6.2. Әлеге карарның бозылуын тикшерү максатыннан ЮХИДИ хезмәткәрләре тарафыннан даими рәвештә рейдлар үткәрергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Ф.Х. Баһаутдинов